| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

**14.08.2017**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 217**

Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләренең автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләренең бер өлешен алу турында

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Р.О. Котельниковның Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге тарафыннан Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләренең автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләренең бер өлешен алу турындагы мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләренең (2 нче кушымта) автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләренең бер өлешен (1 нче кушымта) алырга.
2. Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге арасында, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты исеменнән, һәм Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр белән, муниципаль берәмлекләренең Башкарма комитетлары исеменнән, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән (3 нче кушымта) вәкаләтләрне тапшыру турында, килешү төзергә.
3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә кабул ителгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру, Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләр бюджетларыннан Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган финанс чаралары исәбеннән үтәлә, шулай ук «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге муниципаль берәмлекнең

вәкиллекле органы карары белән каралган очракларда һәм тәртиптә, үз матди ресурсларыннан һәм финанс акчаларыннан өстәмә файдаланырга хокуклы.

4. Әлеге карарны «Зеленодольская правда» газетасында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

5. «Зеленодольск муниципаль районы составына керүче муниципаль берәмлекләрнең, Татарстан Республикасының «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендәге вәкаләтләренең бер өлешен кабул итү турында» 2016 елның 16 июлендәге 121 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, регламент һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы, Советы рәисе** **А. В. Тыгин**

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2017
елның 14 августындагы 217
номерлы карарына
1 нче кушымта

**Алына торган вәкаләтләр исемлеге**

Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге.

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 14 августындагы 217 номерлы карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенә автомобиль юлларыннан файдалану һәм юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә вәкаләтләрен тапшыра торган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына кергән муниципаль берәмлекләр исемлеге**

1. Зеленодольск муниципаль районы Васильево шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге;
2. Зеленодольск муниципаль районы Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге;
3. Зеленодольск муниципаль районы Осиново авыл җирлеге муниципаль берәмлеге.

Зеленодольск муниципаль районы Советының 2017 елның 14 августындагы 217 номерлы карарына

3 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы ______________________авыл җирлеге Башкарма комитеты арасында вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында килешү**

Устав нигезендә эш итүче, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты, ___________________________ Башкарма комитеты җитәкчесе йөзендә, бер яктан, Устав нигезендә эш итүче,_________________ авыл җирлекләре Башкарма комитеты, _________________йөзендә, икенче яктан, бергә «Яклар» дип аталучылар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Россия Федерациясе Бюджет кодексына таянып, түбәндәгеләр турында әлеге килешүне төзеделәр:

1 статья. Килешү Предметы

1.1 Әлеге Килешү Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитетына (алга таба - Районның Башкарма комитеты) ____________________________ җирлекнең вәкаләтләренең бер өлешен тапшыруны беркетә (алга таба - җирлекнең Башкарма комитеты).

1.2 _________________җирлеге Башкарма комитеты Районның Башкарма комитетына түбәндәге вәкаләтләрне тапшыра:

- Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген.

2 статья. Тапшырылган вәкаләтләрне финанс белән тәэмин итү

2.1. Әлеге Килешүне предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру ел саен җирлек бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

2.2 Яклар, әлеге Килешүнең аерылгысыз өлеше булган кушымта буенча, тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен билгели.

3 статья. Якларның хокуклары һәм бурычлары:

3.1. _________________җирлеге Башкарма комитеты:

3.1.1. Район Башкарма комитетының үзенә тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тота. Тәртип бозулар ачыкланган очракта, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү өчен, хәбәр ителгәннән соң билгеле бер вакытта, мәҗбүри булган язма күрсәтмәләр бирә.

3.1.2. Районның Башкарма комитетыннан әлеге Килешүнең 1 статьясында каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле кирәкле мәгълүмат, материаллар, шулай ук әлеге максатларга бирелгән матди ресурслардан һәм финанс чараларыннан файдалану белән бәйле кирәкле документлар соратып ала;

3.1.3. Әлеге Килешүнең 1 статьясында күрсәтелгән, тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда Район Башкарма комитетына консультация һәм методик ярдәм күрсәтә;

3.2. Районның Башкарма комитеты:

3.2.1. Әлеге Килешүнең 1 статьясында каралган вәкаләтләрне, гамәлдәге законнар таләпләренә туры китереп, тиешенчә гамәлгә ашыра;

3.2.2. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча ____________җирлеге Башкарма комитетыннан консультация һәм методик ярдәм ала;

3.2.3. Вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча эшчәнлекне тормышка ашыру өчен махсус вәкаләтле вазыйфаи затларны билгеләүне тәэмин итә;

3.2.4. ____________җирлеге Башкарма комитеты гарызнамәләре буенча тапшырылган вәкаләтләрне үтәүгә бәйле документларны һәм башка мәгълүматны бирә.

## 4 статья. Якларның җаваплылыгы

4.1. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык тотуга нигез булырга мөмкин.

4.2. Якларның берсе әлеге Килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен, гаепле Як башка Якка әлеге Килешүгә кушымтада каралган финанс чаралары күләменең 0,1 % күләмендә штраф сала.

4.3. Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне алга таба үтәүдән азат итми.

4.4. Районның Башкарма комитеты әлеге вәкаләтләр финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен җаваплы.

## 5 статья. Вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тоту

5.1. Әлеге Килешүнең 1 өлешендә каралган Районның Башкарма комитеты вәкаләтләренең үтәлешен контрольдә тоту вәкаләтләрне гамәлгә ашыру турында Районның Башкарма комитеты тарафыннан хисап бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 6 статья. Килешүнең гамәлдә булу срогы, аны туктату тәртибе

6.1. Әлеге Килешү 01.01.2017 елдан үз көченә керә.

6.2. Әлеге Килешүнең гамәлдә булу вакыты 31.12.2017 елга кадәр билгеләнә.

6.3. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

6.3.1. Яклар килешүе буенча.

6.3.2. Берьяклы тәртиптә түбәндәге очракта:

- Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарын һәм (яисә) законнарны үзгәртү (Россия Федерациясе субъекты исеме);

- Якларның берсенең әлеге Килешү нигезендә үз йөкләмәләрен үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве;

- әгәр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаса, йә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр җирлекләр Башкарма комитетлары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә нәтиҗәлерәк гамәлгә ашырылырга мөмкин булса.

6.4. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә берьяклы тәртиптә язма рәвештә җибәрелә. Килешү күрсәтелгән хәбәрнамәне җибәргәннән соң 30 көн узгач, өзелгән дип санала.

## 7 нче статья. Бәхәсләрне хәл итү тәртибе

7.1. Әлеге Килешүне гамәлгә ашыру белән бәйле бәхәсләр, Якларның сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларын куллану юлы белән хәл ителә.

7.2. Килешүгә ирешмәгән очракта, бәхәсне суд тәртибендә, законнар нигезендә карап тикшерелергә тиеш.

## 8 статья. Йомгаклау шартлары

8.1. Әлеге Килешү, ике нөсхәдә төзелгән, Якларның һәркайсы өчен бер үк юридик көчкә ия.

8.2. Әлеге Килешүгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, Яклар тарафыннан өстәмә килешүләр имзалау юлы белән гамәлгә ашырыла.

8.3. Әлеге Килешүдә җайга салынмаган мәсьәләләр буенча Яклар гамәлдәге законнарга таяна.

8.4. Әлеге Килешүнең үтәлешенә бәйле бәхәсләр сөйләшүләр үткәрү юлы белән яки суд тәртибендә хәл ителә.

8.5. Әлеге Килешүгә кушымта итеп бирелә:

- Кушымта: Бюджетара трансфертлар күләме.

## 9. Якларның юридик адреслары һәм реквизитлары:

| | |
|---|---|
| Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе | ______________________җирлеге Башкарма комитет җитәкчесе |
| _________________/__________/ | ____________/_______________/ |
| «____»_____________ 2017 ел | «____»_______ 2017 ел |

Зеленодольск муниципаль
районының Башкарма комитеты
һәм ______________җирлеге
Башкарма комитеты арасындагы
килешүгә
кушымта

**Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме**

Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен ________________ җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.Тапшырыла торган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләме ____________сум тәшкил итә.